МИНИСТЕРСТВО ОБРАЗОВАНИЯ И НАУКИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ МӘГАРИФ ҺӘМ ФӘН МИНИСТРЛЫГЫ

ПРИКАЗ | БОЕРЫК

«02» апреля 2012 г. № 1932/12

Казань

О проведении республиканской
научно-практической конференции учителей
**«Гамил Афзал укулары»**

В целях повышения качества образования, формирования у современного педагога коммуникативной компетенции, активизации творческой и интеллектуальной инициативы, в соответствии с планом Министерства образования и науки РТ на 2011/2012 учебный год 17 – 18 мая 2012 года на базе ГАОУ «Гуманитарная гимназия – интернат для одаренных детей» Актанышского муниципального района проводится научно-практическая конференция учителей «Гамил Афзал укулары». В соответствии с вышеизложенным **приказываю**:

1. Утвердить положение о республиканской научно-практической конференции учителей (Приложение).

2. Контроль за исполнением приказа возложить на начальника отдела национального образования и межрегионального сотрудничества Р.К. Зиннатуллина.

Первый заместитель министра Д.М. Мустафин

Г.А. Ахмадуллина
292-27-74

042144

Приложение к приказу
№1932/12 от 02.04. 2012 года

Республикакүләм «Гамил Афзал укулары»
фәнни-эзләнү конференция
**НИГЕЗЛӘМӘСЕ**

Республикакүләм «Гамил Афзал укулары» фәнни-эзләнү конференциясе күренекле татар шагыйре, Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, Татарстанның халык шагыйре Гамил Афзалның әдәби мирасын өйрәнү, пропагандалау, 2004-2013 нче елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча Татарстан Республикасы дәүләт программасын тормышка ашыру максатыннан үткәрелә.

**МАКСАТЫ:** укытучыларны фәнни-эзләнү эшләренә тарту.

**БУРЫЧЛАРЫ:**
1. Күренекле шагыйрь Гамил Афзал иҗатын өйрәнү;
2. Гамил Афзал исемендәге премия лауреатлары иҗатларын өйрәнү һәм пропагандалау;
3. Укытучыларның фәнни эзләнүләрендә иҗадилыкка омтылыш тәрбияләү, фәнни-тикшеренү күнекмәләрен камилләштерү;
4. Укытучыларның алдынгы эш тәҗрибәсен барлау һәм уртаклашу.

**КОНФЕРЕНЦИЯНЕ ОЕШТЫРУЧЫЛАР**
1. Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрлыгы.
2. Казан (Идел буе) федераль университетының Филология һәм сәнгать институты.
3. Татарстан Язучылар берлеге.
4. Актаныш муниципаль районының башкарма комитеты, Актаныш районы мәгариф бүлеге, Актаныш районы мәгълүмати-методик үзәге.
5. Татарстан Республикасы «Сәләтле балалар өчен гуманитар гимназия-интернат» дәүләт автоном гомумбелем учреждениесе.

**КАТНАШУЧЫЛАР**

Республикакүләм “Гамил Афзал укулары” фәнни-эзләнү конференциясе эшендә гомуми белем бирү учреждениеләренең татар теле һәм әдәбияты, рус теле һәм әдәбияты, инглиз теле укытучылары катнаша ала.

**КОНФЕРЕНЦИЯНЕ ҮТКӘРҮ ШАРТЛАРЫ ҺӘМ ТӘРТИБЕ**

Конференция Татарстан Республикасы «Сәләтле балалар өчен гуманитар гимназия-интернат» дәүләт автоном гомумбелем учреждениесендә үткәрелә.

Чираттагы конференция Г.Афзал премиясенә лаек булган язучылар иҗатына багышлана.

Эшләр татар, рус һәм инглиз телләрендә тәкъдим ителә. Эшләрнең күләме 8 басма биттән артмаска тиеш. Эзләнү эше мастер – класс, проект эше, конкрет методика белән эшкәртелгән практик яки эксперименталь материал характерында булырга мөмкин.

**ХЕЗМӘТНЕҢ ТӘКЪДИМ ИТҮ ТӘРТИБЕ**

Эш төзәтүләрсез, А4 форматында (шрифт Times New Roman – 14, интервал – 1,5; уңнан – 1,5; сулдан – 2,5, астан – 2; өстән – 1,5) компьютерда басылган булырга тиеш. Эзләнү эшләре папкага тегелеп тапшырыла. Презентация өчен таләпләр: Microsoft Power Point 2003 форматында саклана.

Титул битенә белем бирү учреждениесенең тулы исеме, район, укытучының фамилиясе, исеме, әтисенең исеме, тема язылa.

Кереш, йомгак, әдәбият исемлеге, төп өлешнең аерым бүлекләре яңа биттән башлана.

Кулланылган әдәбият исемлеге яңа юлдан алфавит тәртибендә языла.

**ЭЗЛӘНҮ ЭШЛӘРЕНӘ КУЕЛГАН ТАЛӘПЛӘР:**

- хезмәтнең фәнни эш таләпләренә туры килүе;
- укытучының иҗади фикерләү сәләтенә ия булуы, теманы ачу осталыгы;
- фикернең дәлилле, мисалга китерелгән фактларның дөрес булуы;
- эшнең грамоталы язылуы;
- логик эзлеклелектә, нәтиҗәләрнең фәнни дәлилле булуы

Эшләр жюри тарафыннан тикшерелә һәм бәяләнә, таләпләргә туры килгән эшләрнең авторларына конференциядә катнашу өчен чакыру «Сәләтле балалар өчен гуманитар гимназия-интернат» дәүләт автоном гомумбелем учреждениесенең сайтына куела.

Конференциядә чыгыш ясау вакыты 5-7 минут. Укытучы шушы вакыт эчендә эчтәлекне ачып, эш нәтиҗәләре белән таныштыра.

Эшләр (электрон һәм язмача вариантта) заявка, бастыру өчен тезислар белән бергә **2012 елның 1 маена** кадәр түбәндәге адрес буенча җибәрелә:

423740, Татарстан Республикасы, Актаныш районы, Актаныш авылы, Аэропортовская урамы, 3а.

**Конференция нәтиҗәләре буенча җыентык чыгару күздә тотыла** (4 биттән торган статьяны 2012 елның 1 маена кадәр түбәндәге адрес буенча җибәрергә venerahaeva@yandex.ru).

**Заявка үрнәге**

| № п.п. | Фамилия, исем, әтисенең исеме, туган елы | Район, мәктәп № | Адрес, индекс | Телефон | Чыгышка нинди техника кирәклеге турында мәгълүмат |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |

**КОНФЕРЕНЦИЯНЕ ЙОМГАКЛАУ ҺӘМ НӘТИҖӘ ЯСАУ**

- Республикакүләм «Гамил Афзал укулары» фәнни-эзләнү конференциясендә катнашучыларның чыгышы алдан билгеләнгән критерийлар буенча бәяләнә.
- Чыгышлардан соң эксперт комиссиясе утырышы үткәрелә һәм җиңүчеләр турында карар чыгарыла, беркетмә язылა.

Республикакүләм «Гамил Афзал укулары» фәнни-эзләнү конференциясендә катнашучыларга сертификатлар, җиңүчеләргә Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрлыгының дипломнары, истәлекле бүләкләр, нәтиҗәле чыгыш ясаучыларга рәхмәт хатлары тапшырыла.

**БЕЛЕШМӘЛӘР ӨЧЕН ТЕЛЕФОННАР:**
Гимназия-интернат – (85552) 3-26-04; 8 917-257-39-88

Конференцияне оештыру өчен җаваплы: фәнни-эксперименталь эшләр буенча директор урынбасары Хәева – Хәмитҗанова Венера Нәсих кызы

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘГАРИФ ҺӘМ ФӘН МИНИСТРЛЫГЫ
КАЗАН (ИДЕЛ БУЕ) ФЕДЕРАЛЬ УНИВЕРСИТЕТЫ
ФИЛОЛОГИЯ ҺӘМ СӘНГАТЬ ИНСТИТУТЫ
АКТАНЫШ РАЙОН АДМИНИСТРАЦИЯСЕ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ «СӘЛӘТЛЕ БАЛАЛАР ӨЧЕН ГУМАНИТАР ГИМНАЗИЯ – ИНТЕРНАТ»Ы

Мәгълүмати хат

Республика гомуми белем бирү уку йортларының татар теле, әдәбияты, рус теле әдәбияты, инглиз теле укытучыларын **2012 елның 18 маенда үткәреләчәк** Республикакүләм “ГАМИЛ АФЗАЛ УКУЛАРЫ-2012” фәнни-эзләнү конференциясендә катнашырга чакырабыз. Чираттагы конференция Г.Афзал исемендәге премия лауреаты, җәмәгать эшлеклесе, драматург **Туфан Миңнуллин** иҗатына багышлана.

**Конференция эшендә катнашучылар өчен түбәндәге фәнни юнәлешләр тәкъдим ителә:**

I. **Туфан Миңнуллин драматургиясе: заман һәм шәхес**
- әсәрләрендә характерлар һәм конфликт;
- әсәрләрендә шәхес язмышы һәм җәмгыять;
- драмаларында милли мәсьәлә һәм халык язмышы;
- әсәрләрендә чор интеллегенциясенең рухи эзләнүләре
- әсәрләренең тел һәм стиль үзенчәлекләре;
- драматург әсәрләренең тәрбияви әһәмияте;
- Т.Миннуллин әсәрләрен мәктәптә укыту тәҗрибәсе.

II. **Туфан Миңнуллин публицистикасы**

III. **Туфан Миңнуллин – җәмәгать эшлеклесе**

IV. **Русская и английская филология**
- творчество Туфана Миннуллина в сопоставлении с произведениями русских и зарубежных драматургов;
- юмор в драматургии Туфана Миннуллина и в произведениях русских и зарубежных драматургов;
- стратегии лингвокультурной адаптации произведений Туфана Миннуллина при переводе на русский и английский языки.

## ХЕЗМӘТНЕ ТӘКЪДИМ ИТҮ ТӘРТИБЕ:

Эш төзәтүләрсез, А4 форматында (шрифт Times New Roman – 14, интервал – 1,5; уңнан – 1,5; сулдан – 2,5, астан – 2; өстән – 1,5) компьютерда басылган булырга тиеш. Эзләнү эшләре папкага тегелеп тапшырыла. Презентация өчен таләпләр: Microsoft Power Point 2003 форматында саклана.

Титул битенә белем бирү учреждениесенең тулы исеме, район, укытучының фамилиясе, исеме, әтисенең исеме, тема языла.

Кереш, йомгак, әдәбият исемлеге, төп өлешнең аерым бүлекләре яңа биттән башлана.

Эшләр жюри тарафыннан тикшерелә һәм бәяләнә, таләпләргә туры килгән эшләрнең авторларына конференциядә катнашу өчен чакыру җибәрелә.

## ЭЗЛӘНҮ ЭШЛӘРЕНӘ КУЕЛГАН ТАЛӘПЛӘР:

- хезмәтнең фәнни эш таләпләренә туры килүе;
- укытучының иҗади фикерләү сәләтенә ия булуы, теманы ачу осталыгы;
- фикернең дәлилле, мисалга китерелгән фактларның дөрес булуы;
- эшнең грамоталы язылуы;
- логик эзлеклелектә, нәтиҗәләрнең фәнни дәлилле булуы

Эшләр жюри тарафыннан тикшерелә һәм бәяләнә, таләпләргә туры килгән эшләрнең авторларына конференциягә катнашу өчен чакыру җибәрелә.

Конференциядә чыгыш ясау вакыты 5-7 минут. Укытучы шушы вакыт эчендә эчтәлекне ачып, эш нәтиҗәләре белән таныштыра.

Эшләр (электрон һәм язмача вариантта) заявка, бастыру өчен тезислар белән бергә **2012 елның 1 маена** кадәр түбәндәге адрес буенча җибәрелә:

423740, Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Актаныш районы, Актаныш авылы, Аэропортовская урамы, 3а.

Конферениянең эш теле: татар, рус һәм инглиз телләре

***КОНФЕРЕНЦИЯ МАТЕРИАЛЛАРЫН БАСТЫРЫП ЧЫГАРУ КҮЗДӘ ТОТЫЛА***

**Катнашу өчен заявка үрнәге**

| № п.п. | Фамилия, исем, әтисенең исеме, туган елы | Район, мәктәп № | Адрес, индекс | Телефон | Чыгышка нинди техника кирәклеге турында мәгълүмат |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |

## БЕЛЕШМӘЛӘР ӨЧЕН ТЕЛЕФОННАР:

Гимназия-интернат – (85552) 3-26-04; 8 917-257-39-88

**Конференцияне оештыру өчен җаваплы**: фәнни-эксперименталь эшләр буенча директор урынбасары Хәева-Хәмитҗанова Венера Нәсих кызы